СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

14 ноябрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 128 (8140)

Бәясе билгеләнгәнчә

## РЕСПУБЛИКАБЫЗДА, РАЙОНЫБЫЗДА: яңалыклар, фактлар, хәбәрләр

### ГАИЛӘГЕЗ ИМИНМЕ?

Гаиләне планлаштыру. Нәрсә ул? Гаилә - дәүләтнең нигезе, диләр, гаилә иминлеге - дәүләтнең, гомумән халыкның ныклыгы. Шул фәлсәфәдән чыгып гаиләдә килеп туган бихисап проблемаларны хәл итү максатында соңгы елларда гаиләне планлаштыру мәсьәләләре буенча дәүләт программасы эшләп килә. Анда республиканың һәр шәһәрендә, районында үзәк шифаханә базаларында гаиләне планлаштыру бүлекләре оештыру каралган. Шунысын әйтергә кирәк, безнең районда алга куелган яңа төр бурычка җитди карыйлар: Казан, Әлмәт шәһәрләреннән соң Норлатта өченче булып шундый бүлеқ оеша. Һәр көнне көндезге сәгать 2дән 3кә кадәр хатын - кызлар консультациясендә гаилә парларын кабул итү бара. Анда табиблар, башлыча, контрацепция мәсьәләләре турында аңлатмалар белән чыгыш ясыйлар. Сәламәт гаилә булдыру максатында аларны белү гаять мөһим.

### СӘЛАМӘТ БУЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Сәламәт яшәү рәвеше, вакытыннан алда буыннарның хәрәкәтсезлегеннән, ямьсез картлыктан саклану - Норлатта бу мәсьәләләрнең җитдилеген аңлап яшәүчеләр һәм аларны тормыш кагыйдәләре итүче хатын - кызлар да бар. Нәкъ шундыйлар быел район мәдәният йортында оештырылган шейпинг - класска канәгатьлек белән йөриләр. Занятиеләрне мәдәният йортының хореографы О. Җиһаншина алып бара.



Норлат автоюллар идарәсе ягулык - майлау материалларына һичкайчан мохтаҗлык тойганы юк. Биредә үзләренең ягулык салу пунктлары бар аларның. Ә пунктны ягулык - майлау материаллары белән тәэмин итү кебек җаваплы эш шофер Рәис Хуҗахановка йөкләнгән биредә. Рәис исә бик ышанычлы, үтә җитди автотранспортчы. Юл төзелеше кебек мөһим тармакта эшләүче автотранспортны ягулык белән өзлексез тәэмин итү өчен кулыннан килгәннәрнең барысын да эшли ул.

**Рәсемдә: НУАД шоферы Р.Хуҗаханов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## МАТБУГАТ ЧЫГАНАКЛАРЫННАН

### Ялган аракының бугазыннан алырга

Быел республикабызда читтән кертелгән аракы күләме шактый нык кимеде. Чөнки нәрсәне - нәрсәне - ә спиртны, аракыны үзебездә дә кирәгенчә җитештерә алабыз. «Бүген «Татспиртпром» берләшмәсе 7 спирт һәм 11 аракы - ликер заводын үз эченә ала,- ди берләшмәнең генераль директоры Рәшит Шәйхетдинов. - Киләсе елдан без үзебездә җитештергән спиртлы эчемлекләрнең 60 процентын читкә сата алачакбыз. Моның өчен, әлбәттә, иң беренче чиратта сыйфатлы спирт җитештерергә кирәк. Әйтик хәзер Усадта «люкс» тибындагы спирт җитештерү линиясе сафка басты. Тиздән дөньякүләм стандартларга җавап бирүче андый спирт Октябрь районының Төрнәс заводында да җитештереләчәк.»

**P.S. 3 ай буе Казан аракы заводы җитештергән мүк җиләге төнәтмәсендә цинк нормадан 40, ә абрикосныкында 12 тапкырга артып киткән.**

### Һәр минут өчен түлисе

Яңа елдан безне бик күп яңалыклар көтә. Әйтик, акча алышыну (деноминация), фатир өчен түләү бәяләренең артуы, пенсиянең яңача түләнә башлавы... Телефоннары булганнар белеп торсын: 1 гыйнвардан сөйләшкән өчен түләү бәяләренә дә үзгәрешләр керәчәк. Хәзер инде элемтә операторлары сезнең һәр айда күпме сөйләшкәнегезне санап барачаклар. Шуңа күрә һәр телефон хуҗасы белән элемтә бүлекләре аерым килешү төзиячәкләр. Факс хуҗалары тыныч тора алалар - бу хезмәт өчен өстәмә түләү әлегә кертелми. Шулай да чылтыратучының номеры билгеләнә торган телефон хуҗалары аның өчен өстәмә түли башлаячаклар.

### Русия базарында кара сишәмбе

28 октябрь Русия фонд базары тарихына иң караңгы көннәрнең берсе булып керер. Әле дә аның нәтиҗәләре дөнья базарында үзен сиздерә икән. Ул көнне чит ил инвесторлары иртәдән үк Русия акцияләренең пакетларын күпләп сатканнар. Русиялеләрнең кыйммәтле кәгазь базарын даими бәядә тотып торырга чамалары җитмәгәнгә күрә кодировкалар түбәнгә тәгәрәгән. Хәтта кризистан чыгу өчен сатуларны туктатуга кадәр барып җиткәннәр. Бер көн эчендә Русиянең кыйммәтле кәгазьләре уртача 20 процентка түбән тәгәрәп, дәүләткә 12 млрд. доллар зыян китергән. Бигрәк тә Газпром акцияләренең бәясе төшкән.

Русиядәге хәлләр Татарстанны да читләтеп узмагандыр. Безнең җитештерүчеләр дә бу хәлне үз җилкәләрендә сизгәннәрдер. Ни әйтсәң дә, безнең кыйммәтле кәгазьләр белән Мәскәүлеләр идарә итә бит.

Яңалыклар

### Кефир эчегез

Шушы көннәрдә генә Норлат - Октябрь сөт - май комбинатында кефир җитештерә башладылар. Предприятие, мәйданнары кысан булса да, бу мөмкинлекне эзләп тапты. Линиядән һәр көнне ярты тонна файдалы эчемлек чыгарыла. Пакетларга 0,5 литрлы ясап тутырылган продукция шунда ук райпо кибетләренә җибәрелә. Моннан тыш, кефирны комбинатның өч үз кибетеннән дә алырга мөмкин.

### Тиздән авыз итәрсез

**Норлат икмәк заводы.** Предприятие үзенең беренче кондитер товары - ром - баба чыгара башларга әзерләнә. Хәзер аны әзерләүгә кирәкле компонентлар кайтты, җиһазлар урнаштырып көйләнә. Атна - ун көн дигәндә норлатлылар яңа төр продукциядән авыз итә алырлар дип ышанабыз.

Яңалыклар

### Чаралар - яшь китап сөючеләр өчен

Балалар үзәк китапханәсе коллективы мәктәп укучыларының көзге каникулын кызыклы итеп үткәрү өчен зур көч куйды. Беренче көнне үткәрелгән чара «Журналлар иленә сәяхәт» дип аталды. Әлеге кичәне үткәрүче Р.Липатова китап сөюче балаларны мәктәп яшендәге укучылар өчен чыгарыла торган яңа журналлар белән таныштырды. Икенче көн язучы Самуил Маршакның 110 еллыгына багышланган иде. «Маршак төзегән йорт» дип аталган китаплар күргәзмәсе, викторина балалар күңеленә хуш килде. Шәһәрнең икенче мәктәбеннән Дима Цветков һәм Коля Дарьин Маршакның әсәрләрен яратучы, шигырьләрен иң күп яттан белүчеләр итеп танылдылар.

Каникул чорында Т.Тайменева үткәргән кичәләрнең икенчесе әкиятләр иле буенча викторина иде. Анда икенче мәктәптән Илдар Хәйретдинов, беренчедән Лена Рахчеева, Алеша Осипов һәркемне үзләренең зирәк җаваплары белән сокландырдылар. Җиңүчеләргә «татлы» призлар бүләк ителде.

## •РЕСПУБЛИКАБЫЗДА...

### Ак пароход алып китәр...

Киләсе елдан башлап, сәяхәт яратучылар өчен Казан каласыннан Санкт - Петербургка су юлы белән дә барып - кайтып йөрү мөмкин булачак. «Татфлот» компаниясе махсус теплоход сатып алды. Корабның үзенчәлекләре Ладога һәм Онега күлләрендә сынау үтте. Өч палубалы менә дигән теплоход бер рейска 287 кешене алып чыгып китә ала.

Элегрәк бу ак кораб Мәскәү елга пароходчылыгы малы иде. Аның элеккеге исемен үзгәртеп - нитеп тормаска, «Циолковский» дип калдырырга ният ителде.

### Сайлаучыга - яңа журнал

«Избиратель Татарстана» дигән яңа журналның тәүге саны дөнья күрде. Аны Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе гамәлгә куйган. Киләчәктә ул даими чыгарылачак һәм сайлау системасына кагылышлы хокукый белемгә мохтаҗ сайлаучылар һәм сайлауны оештыручылар өчен алыштыргысыз мәгълүмат чыганагы булып торыр.

Тәүге сан Президент М.Шәймиевнең мөрәҗәгате белән ачыла.

## ...РУСИЯДӘ

Борис Ельцинның бишенче оныгы туды. Баланың анасы - Ельциннарның олы кызы Галина Окулова, атасы - «Аэрофлот» генераль директоры Валерий Окулов. 3,4 килограмм авырлыктагы малай Мәскәүдә Үзәк клиник шифаханәнең бала тудыру бүлегендә дөньяга килде. Валерий белән Еленаның ике кызы бар иде инде. Олысына тиздән 18 яшь тула. Шулай да алар бик тә малай көттеләр һәм теләкләренә ирештеләр. Инде биш тапкыр бабай булган Борис Ельцинның күзләрендә шатлык яшьләре җемелдәде.

***

Мәскәүдә 1 ноябрьдән электр энергиясенә, ягулыкка һәм кайнар суга бәяләр арта. Шәһәр хакимияте вәкиленең әйтүенчә, электр плитәләре куелган торак йортларда 1 киловатт - сәгать өчен 150 сум (моңа кадәр 120 иде), ә газ плитәләре куелган йортларда - 210 сум (моңа кадәр 200 иде) түләргә туры киләчәк. Үзәктән җылыту хезмәтләре өчен гомуми мәйданның һәр квадрат метрына 880 сум, ә үзәкләштерелгән кайнар су өчен һәр кешедән 16,2 мең сум алыначак.

# СӘЛАМ ӘТЛЕК

№3


## Табиб киңәше

# ВИРУСЛЫ ГЕПАТИТ

Вируслы гепатит - сары авыруы белән авыру безнең илдә һаман да югары дәрәҗәдә булып кала бирә. Урта Азия республикаларында бу чирнең күрсәткечләре аеруча зур, нормадан 3 - 4 тапкырга артып китәләр. Безнең районда да авыру очраклары бар. Быел Гәйтән, Тимерлек авылларында 21 вируслы гепатит белән зарарланучы теркәлде, шуларның 10сы мәктәп укучылары. Берәр очрак булган урыннар да бар, мәсәлән, Биляр Озеро, Илюткино авыллары, шәһәрнең 4 нче мәктәбе. Киң таралган А вируслы гепатиты белән чирләүнең төп сәбәбе булып инфекциянең авызга эләгүе исәпләнә. Бу эчә торган суның, әйләнә - тирә мохитнең пычрануыннан, су белән тәэмин итү, канализация һәм торак пунктларда санитар чистарту тиешле дәрәҗәдә башкарылмавыннан да килеп чыгарга мөмкин. Мәктәпләрдә шәхси гигиена таләпләрен үтәү өчен шартлар юк, мәктәпкәчә учреждениеләрдә зур тыгызлык, урамнарда колонкалар, коеларның төзексезлеге - болар һәммәсе инфекция таралуга сәбәпче булалар.

Авыру тышкы тирәлектә озак саклана торган вирустан туа. Суүткәргеч трассасын хлорлаганда биредә 20 - 30 минуттан һәлак була, суны кайнатканда ул үлми, бары тик хәлсезләнә генә.

Вируслы гепатит инфекциясе үзен сау - сәламәт дип йөргән кешеләргә авыру кешедән иярә. Ул төрлечә бара, сары формасында да һәм аннан башка да. Симптомнарсыз үткәндә ул иң куркыныч төс ала, чөнки авырулар инфекция чыганагы булып йөрүләрен үзләре дә сизмиләр. Ә сары формасында авыручылар сары төс чыкканчыга кадәр йогышлы, ә аннан соң йогышлылык кими төшә. Эчә торган суның һәм азык - төлек продуктларының пычрануы еш кына гепатитның ачыкланмаган формасы белән чирле кешеләрдән килеп чыга да.

Вируслы гепатит белән авыручыларның яше чикләнмәгән, шулай да нигездә балалар авырый. Сәбәбе - аларның үзара тыгыз бәйләнештә булуында.

Гепатит авыруы июль - август айларында башлана һәм октябрь - ноябрь айларына кадәр дәвам итә, башка чорда ул бик аз санда.

Аңардан ничек сакланырга соң? Башлыча санитар - гигиена таләпләрен үтәү, шуның белән йогышлы чир иярү чылбырын өзү, ягъни авырулар янында сак булу, пычранган азык - төлектән файдаланмау зарури. Халыкны сыйфатлы су һәм азык - төлек белән тәэмин итү, шәхси гигиена таләпләрен үтәү дә мөһим.

Авыру ничек бара соң, сарыны китереп чыгара торган алдагы симптомнар нинди? Вирус белән зарарлану һәм беренче симптомнар барлыкка килүнең арасы 7 көннән алып 45 көнгә кадәр. Авыру кискен башлана, тән температурасы күтәрелә, өшетә, баш авырта, хәлсезлек, аппетит югалуы, косасы килү, эч авырту, уң як кабыргалар астында авырлык, эч кату яки китү күзәтелә. Бу периодта бавыр зурая, ул 5 - 7 көнгә бара, ахырда сидек сыра төсен ала. Бер үк вакытта тизәк тә төссезләнә, күз агы саргая һәм бу авыруның сары стадиясенә күчүен характерлый. Нәкъ шул вакытта еш кына авыру шифаханәгә мөрәҗәгать итә. Бу чорда авыруның хәле уңайлангандай була, ләкин ул чирнең үтүе хакында сөйләми. Шулай 12 - 20 көн үтә, барысы да яхшы булганда бер айдан соң авыру савыга. Бик сирәк очракта аның хроник формага күчүе күзәтелә. А вируслы гепатит белән зарарланучылар һәммәсе дә инфекцион шифаханәләрдә һәм бүлекләрдә дәваланырга тиеш. Тулысынча сәламәтләнү стационардан чыккач 1,5 - 2 айдан соң гына килә. Гепатит кичерүчеләр 6 ай агымында дәвалаучы табиб күзәтүе астында булалар, алар ай саен тикшерүгә килеп торырга тиешләр. Шулай ук авыр физик эштән, командировкалардан, агулы химикатлар белән бәйле эштән, ә укучылар спорт белән шөгыльләнүдән азат ителергә тиешләр. Предприятие җитәкчеләренең аларга аерым игътибар күрсәтүе, сәламәтләнеп 6 ай үткәннән соң аларга курорт шартларында дәвалануны тәкъдим итү зарур.

**И.ТАҺИРОВ,**
**район үзәк шифаханәсенең инфекция бүлеге мөдире.**

# ФИЗЗАЛ ДА, ТРЕНАЖЕР ДА...

«Татнефть - Норлатнефтеразведка» ОООсы санаторий - профилакторие дәвалау корпусының яңа янкормасындагы физиотерапия залы бу көннәрдә үзенең ишекләрен ачачак.Ун кушеткага исәпләнгән бу залда дәваланучылар,шулай ук медицина персоналының нормаль хезмәте өчен бөтен шартлар да тудырылган.

Тренажер залы хезмәтенә мөрәҗәгать итүчеләр дә хәзер аның эшеннән канәгать калырлар.Яңа гына кайтарылган «Тунтури» һәм «Кетлер» фирмасы спорт тренажерларында шөгыльләнү сәламәтлекне ныгыту өчен менә дигән чара.Шул уңайдан янәшәдә үк эшли башлаган шифалы чәй эчү бүлмәсенә кереп,файдалы үләннәр төнәтмәсен дә эчеп чыксаң,үзеңне һичшиксез яшәреп киткәндәй хис итәсең.

Гомумән,бер тапкыр нефтьчеләр санаториенда ял итеп дәваланган кешеләр бирегә тагын да килү теләге белән китәләр моннан.Ләм белән дәвалау,төрле душлар,сәламәтләндерү ванналары,массаж,уңайлыклы ял бүлмәләре,заманаларның авыр булуына да карамастан әйбәт тукланy оештырылу...Шуңа да күпләр,аеруча нефтьчеләр саулык эзләп еракка китмичә,үз профилакторийларында ял итү,дәвалануны кулай күрәләр.

# СОРАГЫЗ? җавап бирәбез

***Газета аша апама киңәш бирсәгез иде. Аның куллары һәм аяклары ярылып эчкә керә. Аягына полиэтилен капчыклар киеп йөри: Полиэтилен капчык үзе үк аякны бетерә бит. Шул ярылып кергән җирләре кып - кызыл. Шул яраларны ничегрәк бетереп була икән?***

* Мондый авыру белән интегүчеләргә атнага 1 - 2 тапкыр чәй содасы һәм нашатырь спирты кушылган кайнар ваннага аякларын тыгып торырга кирәк. 1 литр суга 1 аш кашыгы сода һәм шул ук микъдарда нашатырь спирты алына. Сөял сыман каты урыннарга салицил мае сөртергә һәм, ялтыравыклы кәгазь (вощанка - балавызлы кәгазь) белән төреп, төнгелеккә бинт белән урап куярга кирәк. Табан ярылса, 1 литр суга бер чәй кашыгы сода салып, һәркөнне аякны җылы ваннада тотарга һәм сыек кына марганцовка эремәсендә юып алырга киңәш ителә. Соңыннан синтомицин мае сөртеп урап кую да файдалы.

Аяк табаннары ярылмасын өчен һәр кичне ятар алдыннан җылымса су белән юу һәм крем сөртү зарур.

Куллар ярылса, даруханәләрдән кремнар сатып алыгыз, шулар белән сылагыз.

***Минем кызым 12 яшьтән бирле йоклаганда төн буе тешен шыгырдатып чыга. Тыныч йоклый алмый. Ул нинди авыру икән? Табибларга да күрсәтеп карадым, алар анык кына әйтә алмадылар. Балам өчен борчылам, киңәш бирүегезне сорыйм.***

Балагыз тешләрен шыгырдатып йокласа, мөгаен, аңарда острица (бабасыр), аскаридалар бардыр. Сезгә аны янә табибларга алып барырга кирәк. Аңардан 7 көн дәвамында анализ (соскоб) алырлар, анализлардан соң тиешле даруларын билгеләрләр.

* Эчтә бабасыр булганда бер баш сарымсакны, әрчеп, 1 стакан җылы суда 4 - 5 сәгать төнәткәннән соң, шул ук су белән клизма ясарга кирәк.

* Яшел элпәсе белән бергә кабак төше ашау да файдалы.

* Әстерхан чикләвеген күп итеп бал белән ашаган очракта да яссы, озын кортларны чыгарырга була. Әмма бу вакытта эчне катырмасын өчен эч йомшарткыч ризыклар ашарга кирәк.

* 16 грамм яшь абага үләнен 250 мл. кайнар суда бер сәгать төнәтеп, баллы су белән эчкәндә дә бабасырдан котылып була. Тик бу йөкле хатыннарга ярамый.

**(«Юлдаш»тан).**

## Шифасын күрегез!

# *Чәй яратучыларга иң яхшы чәйләр*

***Һинд чәе (фил рәсеме төшкән).*** Мәскәү чәй фабрикасы чыгара. 125 граммлы капта. Яфрак чәй. Хуш исле, тәмле. 8 баллы шкала буенча бу чәй 7 балл алган. Составында 14,7 процент тинин, 2,6 процент кофеин бар.

***СПЕЦИАЛ. АССАМ ТЕА*** фирмасы чыгара. 100 граммлы капта. Хуш исле. Исе тәмле. Эре яфраклы. 13,6 процент тинин, 2,9 процент кофеин бар.

***ДИЛМАҺ.*** Чыгаручысы - МИФ Гроуп Дилмаһ ЛТД. 125 граммлы капта. Хуш исле, үзенчәлекле тәме бар, күңелне күтәрә. Эре яфраклы чәй. Составында 11,6 процент тинин, 2,6 процент кофеин бар. 7 балл белән бәяләнә.

***Чәй алырга теләсәгез, кибетләрдән шушы чәйне сорагыз.***

* Чәй алганда шуңа игътибар итегез: капта чәй фольга катламы эчендә булырга тиеш. Әгәр чәй гади кәгазьдә яисә полиэтиленга төрелгән булса - алмагыз, бу - әйбәт чәй түгел.

* Бөртекле чәй яхшымы, яфраклымы?

Хикмәт чәй әзерләү технологиясендә генә. «Яфраклысы» - хуш исле, тәмле чәй, ләкин чыгуы көчле түгел. Бөртекле чәй - куе чыга, ләкин хуш исе азрак.

**(«Шәһри Казан»нан).**

# Башта күпме чәч барын беләсезме?



*Бу чәчнең төсеннән тора. Җирәннәрнең башында 9 мең чәч бар, ә ак чәчлеләрнең - 140 мең. Бер чәч 2 - 3 ай яши, аннан соң аны үсеп җиткән икенче чәч алыштыра. Бик куе чәчле кешеләрнең көненә 70 - 100 бөртек чәче коелырга мөмкин - бу нормаль күренеш.*

*Әгәр дә чәч бик нык коелса, табибка мөрәҗәгать итегез.*

*Әгәр дә чәчләр бик тиз һәм күп коелса моңа салкын тию яки ялкынсынган чәч тамырлары сәбәпче булырга мөмкин.*

*Чәч коелмасын өчен аларны сакларга һәм ныгытырга кирәк. Кыш көне яланбаш йөрү һәм юеш чәч белән урамга чыгу зарарлы. Чәчне теләсә нинди шампунь белән түгел, ә сезнең чәчкә яраклы витаминлы шампунь белән генә юарга кирәк.*

*Чәчне юганнан соң, аны яхшылап чайкарга кирәк. Юеш чәчне кайнар һава белән дә киптерергә ярамый.*

